| СОВЕТ ХОЗЕСАНОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ХУҖА ХӘСӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

РЕШЕНИЕ КАРАР

2019 елның 02 нче сентябре Хуҗа Хәсән авылы №15

«Даими нигездә муниципаль вазыйфаны биләүче затларга хезмәт өчен түләү күләме нормативлары, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең, айлык һәм башка өстәмә түләүләр һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибе турында»гы 2018 елның 30 нчы апрелендәге 66 нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында.

«Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында»гы РФ Хөкүмәтенең 2010 нчы елның 26 нчы февралендәге 96 нчы номерлы карары нигезендә («Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү методикасы» белән бергә), Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. «Даими нигездә муниципаль вазыйфаи биләүче затларга хезмәт өчен түләү күләме нормативлары, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләме һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибе турында»гы Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Советы тарафыннан 2018нче елның 30 нчы апрелендәге 3 нче номерлы карарга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 9 нчы номерлы кушымтаның 1 нче пунктында:

«бәлки» «җирле үзидарә органы (Муниципаль орган) җитәкчесе теләгәнчә»сүзтезмәләрен төшереп калдырырга;

«түләргә» сүзен «түләнә»сүзенә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, (http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникаөия челтәренә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Хуҗа Хәсән авыл җирлеге башлыгы Матвеева С.П.